ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы, 422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

08.11.2024 № 9

На № ______________ от ________________

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең
Кызыл-Байрак поселогында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы, 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 28 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл-Байрак поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Кызыл Байрак поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

1. Йорт яны территориясендә түбәндәге адрес буенча гражданнар җыенын уздырырга: Кызыл Байрак поселогы, Үзәк урам, 22 йорт, 16сәг. 30 мин.

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров